| ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**Карар** **Постановление**

№ 002 от «15» 01 2018 г.

Район Башлыгының 2015 елның
3 июнендә кабул ителгән
049 нчы санлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына эшчәнлегенә кұчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча 2017 ел, 29 ноябрь, 01-09/5847 санлы белешмәсе, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 30.07.2010 № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2015 ел, 3 июнь, 049 нчы санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2015 ел, 3 июнь, 049 нчы санлы карары белән расланган административ хокук бозулар турында беркетмә төзергә вәкаләтле затлар билгеләү исемлегеннән административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1 бүлек, 19.4 ст, 19.4.1. ст, 1 бүлек 19.5. ст., 19.7 статьялары белән каралган бүлекне төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.П.Иванов

000109